РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                                            КАРАР

15 сентябрь 2021 ел                                                № 1-26

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә бюджет
процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә , Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2018 елның 16 июлендәге 2-46 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» (12.05.2020 ел, № 1-82, 19.08.2020 ел, № 2-90, 20.10.2020 ел, № 1-4 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 статья:

9 пунктның 6 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен үзләренә беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;»;

1.2. 18 статья:

2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар;

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

дәүләт (муниципаль) программалары (дәүләт (муниципаль) программалары проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары). ».

2. Әлеге карарның 1.2 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл
җирлеге башлыгы А.Ф. Әхмәтҗанов